**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 21 октябрендәге 3636 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 ноябрендәге 3770 номерлы карары белән расланган Клуб, Мамадыш Тракты һәм Зажор урамнары чикләрендәге территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42, 45, 46 статьялары нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 2 февралендәге 112 номерлы «Федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органнары, Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтле башкарма органнары һәм җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә әзерләнә торган территорияне планлаштыру документларын әзерләү, территорияне планлаштыру документларын раслау турында карар кабул итү, мондый документларга үзгәрешләр кертү, мондый документларны яки аның аерым өлешләрен гамәлдән чыгару, мондый документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге тарихи җирлекләр территорияләренә карата территорияне планлаштыру проектын әзерләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында»гы карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 27 июлендәге 722 номерлы «2022, 2023, 2024 һәм 2025 елларда территорияне планлаштыру проектларын, территорияне ызанлау проектларын раслау һәм, җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яки ачык тыңлаулар үткәрмичә, әлеге проектларга үзгәрешләр кертү очракларын билгеләү турында»гы карарына таянып, **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 ноябрендәге 3770 номерлы карары белән расланган Клуб, Мамадыш Тракты һәм Зажор

урамнары чикләрендәге территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектына, әлеге карарның кушымтасы нигезендә планлаштыру һәм ызанлау проектының аерым өлешен раслау юлы белән, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 21 октябрендәге
3636 номерлы карарына
кушымта

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 1 ноябрендәге 3770 номерлы карары белән расланган Клуб, Мамадыш Тракты һәм Зажор урамнары чикләрендәге территорияне планлаштыру һәм ызанлау проектына кертелә торган үзгәрешләр**

II «Территорияне план буенча үстерү характеристикалары турында нигезләмә» бүлегендә 3 «Территорияне һәм социаль хезмәт күрсәтү системаларын план буенча үстерү характеристикалары, төзелеш параметрлары» пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.1.7.9 пунктчасы өстәргә:

«3.1.7.9. кызыл сызыклар ягыннан башлап һәм (яки) өстенлек биреп, беренче катны иҗтимагый-эшлекле функция өчен файдалануның минималь проценты – 20%».

---